ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1–2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.3 статья. **Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә каршылык күрсәтү**

1. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә аларның карарларына йогынты ясау максатында катышкан, аларның законлы таләпләрен вазыйфаи затлар тарафыннан үтәмәгән, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә бүтән рәвештә каршылык күрсәткән өчен –

ике меңнән алып өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан

Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә мәгълүмат (документлар, материаллар, мөрәҗәгатьләргә җаваплар) бирүнең билгеләнгән срокларын вазыйфаи затлар тарафыннан үтәмәгән өчен –

бер меңнән алып ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.”;

2) 8.1 статьяның 6 өлешендә “Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә кагылышлы)” сүзләреннән соң “, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә кагылышлы)” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 елның 14 мае
№ 34-ТРЗ